| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Шланга авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2 апрель 2026 ел 8/1

Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге кайбер муниципаль актларны гамәлдән чыккан дип тану турында

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы "Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны гамәлдән чыгару турында"гы Указының 4 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

1) 2017 елның 31 июлендәге 17/4 "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итү тәртибен раслау турында";

2) 2021 елның 29 июнендәге 10/2 номерлы "Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында мәгълүмат бирү һәм керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы кайбер карарларга үзгәрешләр кертү турында";

3) 2015 елның 5 мартындагы 47/2 номерлы "ТР Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук ТР Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәне раслау турында";

4) 2018 елның 26 октябрендәге 35/2 номерлы "ТР Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук ТР Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында";

5) 2022 елның 3 июнендәге 18/2 номерлы "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында";

6) 2023 елның 29 сентябрендәге 30/1 номерлы "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында".

2. Бу карарны Татарстан Республикасының Хокукый Мәгълүматның Рәсми Порталында бастырып чыгарырга.
3. Бу карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Шланга авыл җирлеге башлыгы: И.И.Якупов